мин «Яшьлегем чәчәк атканда», «Мәхәббәт җимешем син», «Авылымны өзелеп сөям», «Әниемне яратам» кебек тәмле һәм төче сүзләр яза алмадым. Бу хәлне, үземчә, кимчелек түгел дип исәплим. Кырыс наз да (русча чыккан бер китабымның исеме дә «Суровая нежность») җиткән безгә.

Табигатьтә һәрнәрсә гармониядә. Ел һәм Кеше гомере фасыллары да. Кабатланулар һәм яңарулар да, Туу һәм Үлем дә... Һәммәбез шаһит: әнә агачлар ел әйләнәсендә төрле рәвешкә, төрле төсләргә керә. Алар бөреләнәләр, тулышып яфракка әйләнәләр (сүз дә юк, шау яфракта, шау чәчәктә чаклары һәммәбез өчен дә җан рәхәте!), тора-тора саргая башлыйлар, кызгылт төсләргә керәләр, берзаман коелалар, кәүсәләр, ботаклар ялангач, шәрә кала... Бу чакта күпләр аларга битараф, контур сызыклар күзне артык иркәләми... Ә кемнәрдер шул шәрәлектә дә ул агач-тирәкләрнең тагын шау яфракта булачагын күреп сөенә, соклана. Андыйларның күңел күзе дә күрә. Алар аерым затлар. Шигырьне чынлап аңлаучылар да шундыйлардан. Алар син чәчкән орлыклардан дулкынланып торган иген кырларын күз алдына китерә ала. Алар синең соавторларың. Ярты сүздән аңлашуга ни җитә!

Мәгълүм хакыйкать: Шигърият һәм Яшьлек бер иштә йөри. Яшь чакта хисләр саф, күзләр тоныкланмаган, гаҗәпләнү хисе кимемәгән, һәр көн — ачыш, һәрнәрсә кызык, яңа! Яшьлегендә шигырь язып карамаган кеше бик үк нормаль түгел ул, дигәнне дә ишеткәнем бар. Бу китапка кергән бер кыска шигырьдә мондый юллар бар:

> Шигырьне яз яшь чакта —
> күзәнәкләр тулышканда.
> Гомер үтеп, тән кипкәндә түгел!

Ә мин һаман язам әле менә... Каршылыклы хәл. Әйе, тән элеккеге кебек сыгылмалы түгел. (Яшьлекнең дәртен яшьләрнең күләгәсеннән дә белеп була!) Ә баш? Ә күз? Олыгайган саен, зирәгрәк була барасыңдыр, бәлки. Халыкта «Олы кеше — солы төше!» дигән сүз дә бар бит әле! Каршылыклар димәктән, дөнья үзе каршылыклардан тора бит! Дикъкать белән укучылар андый каршылыкларны китаптагы шигырьләрдә дә очратырлар әле.

Әйе, бераз куркыбрак тәкъдим итәм бу яңа шигырьләремне. Укучы ничек кабул кылыр? Аңлармы? Рухи җандашлар табылырмы? Шул ук вакытта үземне тынычландырып юатам да: нигә әле борчылырга? Алдашмыйча, икейөзләнмичә, кешеләрне яратып, үз итеп, чын ихластан яздым бит мин шигырьләремне!

«Вөҗданым белән сөйләшәм, шул минем шигъриятем!»

*Автор*
*2014, 23 июль*

* * *

Талантын да, буй-сынын да
жәлләмичә ишеп биргән.
Ефәктән түгел, каештан
Язмышын да чигеп биргән.
...Бәхет дигән кулъяулыктан
бер чеметем кисеп биргән.

*2001, 2 гыйнвар*
*Аккош күле*

## АК ТӨШ

Күктә — акчарлак.
Суда — ак чабак.
Дулкын өстендә —
күбектә Ак Ат!

Каршыма минем
томырылып килә!
Җайдак соң үзе
күренми нигә?

Җилфер ялларда
әллә ак хәбәр?
Ут-тоякларда
әллә ят хәбәр?

Җаным, тынычлан,
янма ул кадәр!

...Сүзем хак булды,
төшем ак булды!
Каршыма килгән —
хыялымдагы
Акбүз Ат булды!

Күктә ак болыт.
Җирдә — ак канат.
Сабый чагыма
кайтылды кабат.

*2001, 2 гыйнвар*
*Аккош күле*

* * *

Беренче саф хисне
булмас та яңартып,
шулай да мендәрне
иплә әле кабартып!

Әйдә, кемдер йөрсен
гайбәтләр таратып...
Саулыкта сөелү —
байлыктан мең артык!

Тырышсаң буладыр
караны агартып.
Кояшны, Сөюне
булмый ул каралтып!

*2001, 20 февраль*
*Казан*

* * *

Урыс белән дус бул,
биленңдә балтаң булсын!

*Мәкаль*

«Дус»лыгы аның чиксез...

Ил булмагач,
бил сыек...

Өстәвенә
балтасының
сабы сынык.

*2001, 3 март*
*Аккош күле*